СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

# Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы карары

**22 март 2024 ел** **N 8**

## "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Күкчә - Бирәзә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 17 ноябрендә 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Күкчә - Бирәзә авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге уставының 25 статьясына ярашлы рәвештә, Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Күкчә - Бирәзә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендә 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Күкчә - Бирәзә авылында гражданнар җыенын Күкчә - Бирәзә авылы, Үзәк урам, 4 йорт адресы буенча 2024 елның 07 апрелендә 19 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Күкчә - Бирәзә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендә 9 номерлы карарында гражданнар җыены соравын яңа редакциядә бәян итәргә:

Сез 2024 елда Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 250 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналаынр, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы

автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Тынычлык урамының 7 йортыннан 9 йортына кадәр – 20 м,Аркылы урамның 6 йортыннан 10 йортына кадәр – 60 метр юлга нигез салу һәм вак таш җәю )

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

5. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Күкчә - Бирәзә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендә 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны ТР, Арча районы, Күкчә - Бирәзә авылы, Үзәк урам, 4 йорт адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan ru веб-адреслары буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Яңа Кырлай авыл
җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1609012702